# *Хәкимуллина Сәлимә Гыйлаҗетдин кызы*



*Сугыш башланганда мин 4 яшьлек бала булганмын, шуңа күрә ул көннәр хәтеремдә калмаган. Сугышка безнең әти китте. Ул 3 ел буе Сослангерда булды. Әни 5 айлык Сәләхетдин исемле энебезне калдырып, йорт саен ашарга җыеп, чана тартып, этигә ашарга илтеп кайта иде. Ул анда 10 тапкыр барды. Әти сугышка барып җитә алмады, Сослангерда вафат булды. Сугышның бөтен авырлыгы әниләргә төште. Без шул әни янында 3 бала, булдырганча булышып йөрдек. Күңел әрнегән чаклар да бик күп булды. Тормыш авыр, янда әти дә юк. Иркәләнеп ятулар булмады, әти назын күрмәдек. Ярдәм итәр кешебез дә булмады. Әтинең вафат булган хәбәре килгәндә миңа 7 яшь иде. Дөньябыз җимерелгән кебек булды. Әле әтиебез кайтыр, сугыш тиздән бетәр, без дә бәхетле яшәрбез дип өметләнә идек.*

*Минем кечкенә генә капчыгым бар иде, мин шуның белән сәрдә, кычыткан, кузгалак, какы җыеп кайта идем. Күкәрин бәрәңгесе җыйдык. Әни шуннан күмәч , күкәрин талканы пешерә иде. Сәләхетдин белән бергә 4 әр чиләк бәрәңге игә идек. Әни аннан кабартма пешерә иде. Ул бик тәмле була иде. Сыер асрадык, сөтебез булды. Әни маен сата, без күбеген ашый идек. Кече Битаман авылында 4 класс белем алдым. Аннан соң укырга мөмкинлек булмады. Үсмер вакытларда колхозда яшелчә үстерүдә эшләдем.*

*Сугыш барган яклардан кайткан танышларым булмады. Сугышчыларга да әйберләр җибәрә алмадык.*

*Сугыш вакытында мин 4-9 яшьлек бала идем. Ул вакытта мин хезмәт куймадым. Дәүләттән дә бернинди бәяләү күрмәдек. Пионер, комсомол оешмалары турында да берни әйтә алмыйм.*

*Сугыш бетү хәбәрен әниләрдән ишеттек. Шатландык, ләкин шатлыгыбыз китек булды: сугыш безне әтисез калдырды. Исән калганнар сугыштан кайтты. Әтиләре сугыштан кайткан балаларга кызыгып карый идек. Сугыштан соң да тормышлар бик авыр булды. Укырга мөмкинлек булмады. Яшелчә үстерүдә, аннан сыер савуда эшләдем. Шулай итеп тормышны алып бардык инде.*

*Хәзерге балалар тыныч, мул тормышның кадерен белеп яшәсеннәр иде. Тырышып укысыннар, хәзер аңа бөтен мөмкинлекләр дә бар, безгә ул эләкмәде. Ризыкның, малның кадерен белсеннәр, әрәм итмәсеннәр. Сугыш вакыты булмаса да, авыр тормышлы кешеләр хәзер дә бар. Аларга ярдәм итсеннәр, алардан гыйбрәт алсыннар иде. Әти-әнинең кадерен белеп, аларга борчу китермичә, игелекле, мәрхәмәтле булып яшәүләрен телим.*